**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**8 август, 2019 ел** **№ 115**

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлеге Советының «Иске Барыш авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын һәм терлекләрне тоту кагыйдәләрен раслау турында» 2009 елның 5 апрелендәге 97 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»

«Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 27.12.2018 ел, № 498-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлеге Советының «Иске Барыш авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын һәм терлекләрне тоту кагыйдәләрен раслау турында» 2009 елның 5 апрелендәге 97 номерлы карарына (алга таба-карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарга 1 нче кушымтаның 2 пунктындагы өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«йорт хайваннары - хуҗасы-физик зат карамагында булган хайваннар (асралуга тыелган хайваннар исемлегенә кертелгән хайваннардан тыш), аның вакытлыча яки даими күзәтүе астында булган һәм аларны тоту урыны зоопарклар, зоосадлар, цирклар, зоотеатрлар булмаган хайваннар;».

2. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Иске Барыш авылы, Үзәк урамы, 15;

- ТР, Кама Тамагы районы, Кыртапа авылы, Мәктәп урамы, 10,

шулай ук Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

«Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Иске Барыш авыл җирлеге»
Башлыгы, «Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Иске Барыш авыл җирлеге»
Советы рәисе И.Р. Җиһаншин